СОВЕТ МАЙДАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МӘЙДАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ — КАРАР

10.08.2026 с.Майдан № 14 – 69

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сораштыру билгеләү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге территориясендә гражданнардан сорашып белешүне билгеләү һәм үткәрү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге Советының 29.03.2013 ел № 27 – 145 карары белән (24.05.2021 ел № 8 – 53 үзгәрешләре белән),

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлеге территориясендә «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 13нче филиалы Урман участогы авылы клубын бетерү мәсьәләсе буенча халык фикерен ачыклау максатында, исемле тавыш бирү рәвешендә гражданнардан сораштыру үткәрүне билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- сораштыруны үткәрү датасы һәм вакыты - 27.08.2026 ел 8.00 дән 20.00 гә кадәр;

– сораштыру үткәрү урыннары-Мәйдан авыл җирлегендә яшәүчеләрне теркәү урыны буенча.

3. Сораштыру исемлекләре буенча исемләп тавыш бирү үткәрергә.

4. Гражданнардан сораштыру үткәргәндә сораштыру исемлегенә кертү өчен түбәндәге сорауның формулировкасын расларга: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 13нче филиалы Урман участогы авылы клубын бетерүгә ризамы?»

5. Сораштыру үткәрү буенча комиссия төзергә һәм аның составын расларга (1 нче кушымта).

6. Сораштыру исемлегенең формасын һәм текстын расларга (2 нче кушымта).

7. Югары Ослан муниципаль районының Мәйдан авыл җирлегендә сораштыруда катнашучы 80 кешенең минималь санын билгеләргә.

8. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Совет рәисе урынбасары,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Мәйдан авыл җирлеге башлыгы урынбасары В.Е. Сафонова

Мәйдан авыл җирлеге
Советының 2026 елның
10 августындагы
14 – 69 номерлы карарына
1 нче кушымта

Гражданнардан сораштыру үткәрү

КОМИССИЯСЕ СОСТАВЫ

1. Файзрахманова Зилә Накиф кызы – Мәйдан авыл җирлеге башлыгы
2. Коновалова Елена Юрьевна – Мәйдан авыл җирлеге секретаре
2. Сафонова Валентина Евгеньевна – Мәйдан авыл җирлеге депутаты
3. Яманова Наталья Викторовна – Мәйдан авыл җирлеге депутаты
4. Малафеева Валентина Ивановна – Мәйдан авыл җирлеге волонтеры

Мәйдан авыл җирлеге
Советының 2026 елның
10 августындагы
14 – 69 номерлы карарына
2нче кушымта

СОРАШТЫРУ КӘГАЗЕ

Сораштыру үткәрелә торган сорауны формалаштыру: «Югары Ослан муниципаль районының Үзәкләштерелгән клуб системасы» МБУнең 13нче филиалы Урман участогы авылы клубын бетерүгә ризамы?»

| Фамилия, исеме, атасы исеме | Туган көне, ае һәм елы | Яшәү урыны адресы | Дата | Тавыш бирү тамгасы | | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | риза | каршы | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Комиссия рәисе______________________________ ______________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)

Комиссия секретаре ______________ ______________ ______________
(имза) (имзаның расшифровкасы) (дата)